ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

19 октябрь 2020 ел | № 5374

Гражданнар оборонасы һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны әзерләү турында

Татарстан Республикасының «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Законы, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» 2020 елның 13 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау турында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар оборонасы һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы халкын әзерләүне оештыру турында» 2016 елның 20 маендагы 331 номерлы карары, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Гражданнар оборонасы һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны әзерләү турында нигезләмәне расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе | Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 19 октябрендәге
5374 номерлы карарына
кушымта

Гражданнар оборонасы һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны әзерләү турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә гражданнар оборонасы һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны әзерләүнең төп бурычларын, формаларын һәм тәртибен билгели.

2. Гражданнар оборонасы бурычларын үтәүдә катнашу, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча белемнәр, осталык һәм күнекмәләр дәрәҗәсенә карап, халык гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә әзерлек үтәргә тиешле түбәндәге төркемнәргә бүленә:

1) гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системасы составына кертелгән, шәһәр территориясендә урнашкан оешмалар җитәкчеләре;

2) гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә бурычларны хәл итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органнары һәм оешмалар хезмәткәрләре;

3) гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе рәисе, икътисадның тотрыклы эшләвен тәэмин итү комиссиясе рәисе, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә махсус вәкаләтле идарә органнары җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары, оешмалар җитәкчеләре;

4) белем бирү оешмаларында укучы затлар;

5) җитештерү һәм хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшләүче, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системасы составына кертелмәгән затлар;

6) җитештерү һәм хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшләмәүче затлар.

3. Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны әзерләү буенча төп бурычлар:

1) халыкның барлык төркемнәрен үз-үзеңне тоту кагыйдәләренә, гадәттән тыш хәлләрдә саклануның төп ысулларына һәм эш итүләргә, зыян күрүчеләргә беренче медицина ярдәме күрсәтү алымнарына, индивидуаль һәм күмәк саклану чараларыннан файдалану кагыйдәләренә өйрәтү;

2) оешма җитәкчеләрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системасы составына керүче көчләр һәм чаралар белән идарә итү күнекмәләре булдыру;

3) оешма җитәкчеләренең, шулай ук комиссия рәисләренең гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә чаралар оештыру һәм үткәрү буенча практик күнекмәләрен камилләштерү;

4) вәкаләтле хезмәткәрләр тарафыннан өйрәнүләр һәм тренировкалар барышында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы эше кысаларында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системасы эшчәнлегенең төрле режимнарында, шулай ук авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкарганда эш итүләр тәртибен практик үзләштерү.

## 2 бүлек. Әзерлекне оештыру

4. Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны әзерләүне үз компетенциясе кысаларында җирле үзидарә органнары һәм оешмалар җитәкчеләре оештыра һәм гамәлгә ашыра.

5. Гражданнар оборонасы һәм хәрби хәрәкәтләр алып барганда яки әлеге хәрәкәтләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны әзерләү гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны әзерләүнең бердәм системасы кысаларында гамәлгә ашырыла.

6. Халыкны әзерләү дифференциацияләнгән рәвештә (төркемнәрдә) әзерләү (яңадан әзерләү) һәм квалификация күтәрүгә җәлеп итү юлы белән, махсус программалар буенча үткәрелә торган планлы дәресләрдә, мөстәкыйль әзерлек юлы белән, шулай ук гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча укыту-методик сборларда катнашканда гамәлгә ашырыла.

7. Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау мәсьәләләре буенча укулар белем бирү оешмаларында, квалификация күтәрү оешмаларында, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча укыту-методик үзәгендә, Татарстан Республикасы укыту-методик үзәгенең Яр Чаллы шәһәрендәге филиалында, турыдан-туры эш һәм яшәү урыны буенча үткәрелә.

8. Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны әзерләү түбәндәге формаларны күздә тота:

1) эшләүче халык өчен - тәкъдим ителә торган программалар нигезендә эш урыны буенча дәресләр үткәрү һәм гадәттән тыш хәлләрдә эш итү тәртибен мөстәкыйль өйрәнү, алган белемнәрне һәм күнекмәләрне алга таба өйрәнүләрдә һәм тренировкаларда ныгыту;

2) эшләмәүче халык өчен - әңгәмәләр, лекцияләр үткәрү, уку фильмнары карау, яшәү урыны буенча өйрәнүләргә һәм тренировкаларга җәлеп итү, шулай ук уку әсбаплары, белешмәлекләр, листовкалар һәм буклетларны мөстәкыйль өйрәнү, массакүләм мәгълүмат чараларында гадәттән тыш хәлләрдән саклау мәсьәләләре турындагы материаллар белән танышу;

3) укучылар өчен - «Тормыш иминлеге нигезләре» курсы һәм «Тормыш иминлеге» дисциплинасы кысаларында тиешле программалар буенча уку вакытында дәресләр үткәрү;

4) гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе рәисе һәм әгъзалары, гражданнар

оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә вәкаләтле хезмәткәрләр, икътисадның тотрыклы эшләвен арттыру комиссиясе рәисе, коткару хезмәтләре (гражданнар оборонасы хезмәтләре) җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары, шәһәр гражданнар оборонасы һәм эшләүчеләр саны 200 дән артык булган оешмалар җитәкчеләре, һөнәри белем бирү оешмалары җитәкчеләре, шәһәр һәм оешмаларның штатныкы булмаган авария-коткару формированиеләре (ШБАКФ) (командалар) һәм гражданнар оборонасы чараларын үтәүне тәэмин итү буенча штатныкы булмаган формированиеләр (ГОШБФ) (командалар) җитәкчеләре өчен – квалификация күтәрү биш елга бер тапкырдан да ким түгел, мөстәкыйль эш үткәрү, шулай ук сборларда, өйрәнүләрдә һәм тренировкаларда катнашу.

9. Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә вазыйфалар үтәүгә бәйле вазыйфага беренче тапкыр билгеләнгән затлар өчен әзерлек (яңадан әзерләү) яки квалификация күтәрү беренче ел эшләү дәвамында мәҗбүри булып тора.

10. Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә квалификация күтәрүне узалар:

1) гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе рәисе һәм әгъзалары, икътисадның тотрыклы эшләвен арттыру комиссиясе рәисе, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә бурычларны хәл итүгә вәкаләтле хезмәткәрләр, Башкарма комитетның структур бүлекчәләре һәм оешмалар җитәкчеләре, коткару хезмәтләре (гражданнар оборонасы хезмәтләре) җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары, шәһәр гражданнар оборонасы һәм гражданнар оборонасы буенча категорияләргә кертелгән оешмалар (эшләүчеләр саны 200 дән артык булган) җитәкчеләре, һөнәри белем бирү оешмалары җитәкчеләре, шәһәр һәм оешмаларның штатныкы булмаган авария-коткару формированиеләре (ШБАКФ) (командалар) һәм гражданнар оборонасы чараларын үтәүне тәэмин итү буенча штатныкы булмаган формированиеләр (ГОШБФ) (командалар) җитәкчеләре - Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча укыту-методик үзәгендә;

2) эшләүчеләр саны 200 гә кадәр булган, гражданнар оборонасы буенча категорияләргә кертелмәгән оешмалар, мәктәпкәчә белем бирү оешмалары җитәкчеләре, руханилар, оешмаларның дежур-диспетчерлык хезмәтләре җитәкчеләре һәм белгечләре, штатныкы булмаган формированиеләр (ШБАКФ, ГОШБФ) (звенолар, төркемнәр, постлар, станцияләр) җитәкчеләре, укулар җитәкчеләре, укыту-консультация пунктлары инструкторлары, башлангыч 1-4 сыйныф укытучылары, белем бирү оешмаларының 5-8 сыйныф җитәкчеләре, шәһәрдән читтәге балалар сәламәтләндерү базалары (лагерьлары) администрациясе – Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча укыту-методик үзәге филиалында;

3) «Тормыш иминлеге» дисциплинасы укытучыларының һәм «Тормыш иминлеге нигезләре» курсы оештыручы-укытучыларының квалификациясен күтәрү - Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча укыту-методик үзәгендә.

11. Гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкның белемен,

осталыгын һәм күнекмәләрен камилләштерү команда-штаб, тактик-махсус һәм комплекслы өйрәнүләр һәм тренировкалар үткәрү барышында гамәлгә ашырыла.

12. Өч тәүлеккә кадәр дәвамлылыктагы команда-штаб өйрәнүләре җирле үзидарә органнарында - өч елга бер тапкыр үткәрелә. Оешмалардагы команда - штаб өйрәнүләре яки штаб тренировкалары елга бер тапкыр бер тәүлеккә кадәр дәвамлылыкта үткәрелә.

13. Сигез сәгатькә кадәр дәвамлылыктагы тактик-махсус өйрәнүләр авария-коткару хезмәтләре һәм оешмаларның авария-коткару формированиеләре катнашында өч елга бер тапкыр, ә даими әзерлектәге формированиеләр катнашында елына бер тапкыр үткәрелә.

14. Ике тәүлеккә кадәр дәвамлылыктагы комплекслы өйрәнүләр куркыныч җитештерү объектлары булган оешмаларда өч елга бер тапкыр үткәрелә. Башка оешмаларда өч елга бер тапкыр сигез сәгатькә кадәр дәвамлылыктагы тренировкалар үткәрелә.

15. Белем бирү оешмаларында тренировкалар ел саен үткәрелә.

16. Гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә өйрәнүләргә һәм тренировкаларга җәлеп ителә торган затларга аларны үткәргәндә хәвеф-хәтәр ихтималы турында хәбәр ителә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы — Н.И. Галиева